## *Утыз Имән авылының тарихы.*

*Яңа Кади авылында яшәүчеләр авылның исемен аңа беренче нигез салучы - татар Кади белән бәйлиләр. Моны раслаучы кайбер аргументлар да бар. Авылның мәктәп музеенда гаять кыйммәтле һәм инандыргыч документ әлеге татар Кадиның шәҗәрәсе саклана. Ул үзенә җиде буынны алган: Кади - Хөсәен - Гайсә - Хөремша – Бадамша – Батырша - Мөхәммәтшәриф. Кади нәселенең соңгысы - Мөхәммәтшәриф 1820 елда туган. Һәр буынга 30 ар ел бирсәк тә, 1820 нче елдан артка күчереп санагач 180 ел була. Нәселгә нигез салучы бу урынга килгәндә инде бик яшь кеше булмавын исәпкә алсак, бу авылның оешу датасын якынча 1655 дип уйларга мөмкин,чөнки нәкъ менә Беренче Кама арты сызыгы чорында монда беренче оешкан төстә күченүчеләр барлыкка килгән. Әлеге Кади дәүләт хәрби хезмәтендә торучы кеше була, шуңа күрә аңарга җир бирәләр, ә ул утарын үз исеме белән атый. Ә калган күченеп килүчеләр, мисалга, качып китүчеләр, андый хокукка ия булмыйлар.Бу якларны колонизацияләү башлангач, җир бүлеп бирә, ә ул үз исеме белән яңа авылга нигез сала...*

*Ләкин бу авылны озак еллар дәвамында Утыз Имән дип атап йөртәләр. 18 гасыр ахырындагы дәүләт кәгазьләрендә (ревизия) ул “Кади,Утыз Имән” дип теркәлгән.18 гасырда бу авылның нәкъ шундый исем белән аталып йөртелүе турында тагын бер факт сөйли: 1754 елда биредә туган татар халкының атаклы мәгърифәтчесе, шагыйре һәм философы Габдерәхим авылның исемен үзенә псевдомин итеп ала. Шагыйрьнең тулы исеме: Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари, ягъни Болгардагы Утыз Имән авлыннан Габдерәхим.*

*Шулай да Утыз Имән атамасы каян килеп чыккан соң?Авылга Кади исеме бирелгәннән соң барлыкка килгән атама түгеллеге ачык күренә.*

*Утыз Имән авылы бу тирәгә хәрби хезмәттәге дәүләт кешесе Кади килгәнче үк яшәгән.*

*Монда күршедәге Кармәт Утыз Имәндәге кебек (хәзерге Ульяновка) чувашлар яшәгән.Ләкин аларның монда яшәргә законлы хокуклары булмаган, чөнки күпчелек өлеше качкыннардан торган. Шул*

*сәбәпле аларның җирләрен тартып алып өлешчә Кадига биргәннәр, гадәттә ул 40 дисәтинәдән артмаган.*

*Бу факт крайны өйрәнүче тарихчылар өчен тагын шунысы белән мөһим: чувашлар Кама арты ныгытма сызыгы төзелгәнче үк (1652-1656) күптән яшәгәннәр.Алар абориненнар,ягъни җирле халык булганнар, яки Казан ханлыгы җимерелгән чорда Казан яныннан качкан беренче мөһаҗирләр булуы мөмкин (1552-1557).*

*Чувашларның Казан ханлыгы чорында хәзерге Чувашия территориясендә, Иделнең уң як ярында гына түгел, ә Казан ханлыгының үзендә, Иделдән Вяткага кадәр җирләрдә дә яшәгәнлекләре билгеле.*

*Татарстан территориясендә Кармәт исемле бернечә авылның булуы да Чирмешән чувашларның барлыкка килүендә Казан ханлыгы вариантын бөтенләй чуттан төшерми. Андый атамалы авыллар Вятка елгасы төбә- гендә, Аксубай зонасында, бездә дә бар.*

*Яши-яши Утыз Имән исеме онытыла бара,моңа сәбәп тә була: бу авылда чувашлар азайганнан-азая, озакла- мый авылның икенче,татар исеме генә кала-Кади.*

*Хәзер авылның исемен яңадан кайтардылар, ләкин инде монда кайчандыр яшәгән чувашлар хөрмәтенә түгел,ә мәгърифәтче Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгариның истәлегенә.*

*Янә документларга әйләнеп кайтыйк.1780 елгы кәгазьләре буенча"Кади Утыз Имәндәт 66 хәрби хезмәт татары һәм аларның 1 йорт хезмәтчесе, барлыгы 67 ир-ат яши".Менә шул "йорт хезмәтчесе" булу бик әһмият -ле факт: андый хезмәтчеләрне бары тик бай кешеләр генә яллый алганнар. Хәрби хезмәттәгеләргә җир бирсәләр дә ялчылар бирү тиеш булмаган. Хәрбиләр андый ялчыларны крестьяннар арасыннан алганнар.*

*1780 елга исә хәрби хезмәттәгеләрнең ялчы тотарга хәлләреннән килми башлый, шуңа бөтен бер авылда бары бер йорт хезмәтчесе кала.*

*1858 елда авылда 731, тагын кырык елдан-1488*

*ә 1906 елда 319 гаиләдә 1737 кеше яши. 1858 елда 1 ир-атка 6 шар дисәтинә исәбеннән, ә барлыгы 2867 дисәтинә җир бүлеп бирелгән була. Җир ышаныкы була,хосусый җир биләүчеләр турында миндә*

*мәгъ -лүмәтлар юк, бәлки 1917 ел революциясе алдыннан алар барлыкка килгән булганнардыр.*

*1930 елда кулаклардан җирне тартып алу башлангач, авылның крестьяны Хөснелгата Нуруллинны революциягә кадәр 100 дисәтинә җирле булуда “гаеплиләр”.Күмәкләштерү чорына авылда 1199 кеше яши: сугышлар,революцияләр һәм ачлык халыкны сирәгәйтәләр.Күмәкләштерү, билгеле, көчләп үткәрелә.Минем эзләнүләрем буенча 4 гаилә “ раскулачивать” ителеп 1930-1931 елларда Себергә сөрелә, 1932 елда 13 кулак кулга алынырга тиеш була.*

*Бусы-советлар чоры тарихы, аны җирлетарихчылар яхшы белә.*

*Яңа Кади – республикада танылган авыл.Аның турында, Габдерәхим Утыз Имәни турында революциягә кадәр татар тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗәни дә язып чыккан.*

Мемориаль үзәк мөдире
Н.Фролов язмасыннан.